Аксубай муниципаль районы
Сергеевский авыл жирлеге Советы
423050Аксубай районы,ЯңаҮзиавылы
Мәктәпурамы, 7 нчейорт

Совет Беловского сельского
поселения Аксубаевского
муниципального района
423050Аксубаевский
район,с.НовоеУзеевоулица
Школьная, д.7

Тел. (8-84344-4-08-19) ОГРН 1061665003212,
ОКПО 04306440, ИНН/КПП 1603005000/160301001
E-mail: *Belov.Aks@tatar.ru,sovet.belov@mail.ru*

Татарстан Республикасы Аксубай муниципаль районы
Беловка авыл җирлеге башлыгы

КАРАР

**№3** **15.11.2024 ел**

«Аксубай муниципаль районы Беловка авыл җирлегенең
Сергеевский поселогында гражданнарның
үзара салым акчаларын кертү һәм куллану мәсьәләсе буенча
гражданнар җыенын билгеләү турында".

«Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 06 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль законның 25.1, 56 статьялары, «Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында» 2004 елның 28 июлендәге 45-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законының 35 статьясы, Аксубай муниципаль районының «Беловка авыл җирлеге» муниципаль берәмлеге Уставының 24 статьясы нигезендә

Карар бирәм:

1. 2024 елның 25 ноябрендә 12 сәгать 00 минутка мәдәният йорты бинасында билгеләргә: ТР, Аксубай районы, п..Сергеевский ур., Зеленая ур., 1 йорт Татарстан Республикасы Аксубай муниципаль районының Беловка авыл җирлегенең Сергеевский авыл җирлегенә үзара салым кертү мәсьәләсе буенча гражданнар җыены.

2. Гражданнар җыенына чыгарыла торган мәсьәләне расларга«Татарстан Республикасы Аксубай муниципаль районы Беловка авыл җирлегенең Сергеевский поселогы территориясендә яшәү урыны буенча теркәлгән балигъ булган һәр кешедән, 1 төркем инвалидлардан, көндезге бүлектә укучы студентлардан, Россия Армиясе сафларына хәрби хезмәткә чакырылган гражданнардан, махсуслаштырылган хәрби операциягә мобилизацияләнгән, (контракт буенча хәрби хезмәткәрләр, мобилизацияләнгәннәр) һәм аларның гаилә әгъзаларннан тыш (бергә яшәүче ата-аналар), ир белән хатын, балигъ булган балалар) 2025 елда 500 сум күләмендә үзара салым җыярга, алынган акчаларны түбәндәге эшләрне башкару буенча җирле әһәмияттәге мәсьәләләрне хәл итүгә юнәлтергә сез ризамы:

**1.Җирлекнең торак пунктлары чикләрендәге җирле әһәмияттәге автомобиль юлларына карата юл эшчәнлеге**.

- Торак пункт чикләрендә гомуми файдаланудагы җирле әһәмияткә ия автомобиль юлларын төзү, ремонтлау, карап тоту (Сергеевский торак пункты чикләрендә юл полотносын төзү, шул исәптән: туфрак күтәрү, гредировкалау, вак таш

сибү, тигезләү (эшләр һәм хезмәт күрсәтүләр өчен шартнамә буенча түләү, вак таш сатып алу, авыл юлларына вак таш салу)

Беловка авыл җирлеге Сергеевский торак пункты чикләрендә юлны кышкы карап тоту (юлларны кардан чистарту,запас частьләр һәм җайланмалар сатып алу; эшләр һәм хезмәт күрсәтүләр өчен килешү буенча түләү, ягулык-майлау материаллары сатып алу).

**2. Җирлек торак пунктлары чикләрендә янгын куркынычсызлыгының беренчел чараларын тәэмин итү:**

- янгын куркынычсызлыгының беренчел чараларын тәэмин итү (Сергеевский бистәсе өчен янгын сүндерү өчен савытлар һәм аңа комплектлау әйберләре сатып алу).

н сүндерү өчен савытлар һәм аңа комплектлау әйберләре сатып алу).

« РИЗА» «КАРШЫ».

3. Әлеге карарны Беловка авыл җирлегенең мәгълүмат стендларында, Татарстан Республикасы Аксубай муниципаль районының Интернет челтәрендәге рәсми сайтында урнаштырып, түбәндәге адрес буенча бастырып чыгарырга: http://aksubayevo.tatarstan.ru) һәм Татарстан Республикасының рәсми хокукый мәгълүмат порталында бастырып чыгарырга (http://pravo.tatarstan.ru).

4. Әлеге карар басылып чыккан көненнән үз көченә керә.

Аксубай муниципаль районы
Беловка авыл җирлеге башлыгы И. Р. Мәхмүтов

СОВЕТ БЕЛОВСКОГО СЕЛЬСКОГО ПОСЕЛЕНИЯ